КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 декабрь г.Казань № 1274

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636; 2017 ел, 15 май, 282 нче; 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 205 нче; 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче; 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче; 2020 ел, 2 март, 155 нче; 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче карары редакциясендә)

Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшли торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс төркемнәре

| Төркемнәр | Муниципаль берәмлек исеме | 2021 елның 1 декабренә территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | Заявкаларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I төркем – шәһәр округлары | Казан шәһәре | 77 | 39 |
| | Яр Чаллы шәһәре | 77 | 39 |
| | Барлыгы | 154 | 78 |
| II төркем – халкы 60 мең кешедән күбрәк булган шәһәр җирлекләре | Әлмәт шәһәре | 36 | 18 |
| | Бөгелмә шәһәре | 3 | 2 |
| | Алабуга шәһәре | 16 | 8 |
| | Зеленодольск шәһәре | 4 | 2 |
| | Лениногорск шәһәре | 13 | 7 |
| | Түбән Кама шәһәре | 26 | 13 |
| | Чистай шәһәре | 8 | 4 |
| | Барлыгы | 106 | 54 |
| III төркем – халкы 60 мең кешедән күбрәк булган шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлек-ләре | Әгерҗе шәһәре | 7 | 4 |
| | Азнакай шәһәре, Азнакай муниципаль районы составына керә торган Актүбә шәһәр тибындагы поселогы | 17 | 9 |
| | Алексеевск муниципаль районы составына керә торган Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы | 3 | 2 |
| | Арча шәһәре | 5 | 3 |
| | Баулы шәһәре | 16 | 8 |
| | Буа шәһәре | 6 | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Чүпрәле муниципаль районы составына керә торган Иске Чүпрәле авыл җирлеге | 1 | 1 |
| | Алабуга муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 14 | 7 |
| | Зәй шәһәре | 11 | 6 |
| | Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы | 4 | 2 |
| | Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган барлык шәһәр һәм авыл җирлекләре | 21 | 11 |
| | Кукмара шәһәре | 4 | 2 |
| | Лаеш шәһәре һәм Лаеш муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 29 | 15 |
| | Мамадыш шәһәре, Мамадыш муниципаль районы составына керә торган Красная Горка авыл җирлеге | 9 | 5 |
| | Менделеевск шәһәре | 5 | 3 |
| | Минзәлә шәһәре | 5 | 3 |
| | Түбән Кама муниципаль районы составына керә торган Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | 2 | 1 |
| | Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 13 | 7 |
| | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы | 6 | 3 |
| | Сарман муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 3 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Болгар шәһәре | 1 | 1 |
| | Тәтеш шәһәре | 5 | 3 |
| | Тукай муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 4 | 2 |
| | Ютазы муниципаль районы составына керә торган Урыссу шәһәр тибындагы поселогы | 1 | 1 |
| | Барлыгы | 192 | 104 |
| Барысы | | 452 | 236 |